**Юзеев И.Г.**

Кар өстендә дөяләр

Балалар өчен шигырьләр

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Ю25

**Төзүчесе**

***Ленар Шәех***

**Рәссамы**

***Рөстәм Хәбибуллин***

**Юзеев И.Г.**

Кар өстендә дөяләр: балалар өчен шигырьләр / Илдар Юзеев; төз. Л.Шәех. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. — 63 б. — 5000 д. — ISBN 978-5-298-01628-5

Китапта Татарстан Республикасының халык шагыйре Илдар Юзеевның балалар өчен язылган берсеннән-берсе самими, ихлас, якты шигырьләре тупланган.

ISBN 978-5-298-01628-5
© Татарстан китап нәшрияты, 2008
© Шәех Л.М., төзү, 2008

# Сабый җанлы Илдар абый

Кайчандыр арабызда Илдар абый Юзеев дигән шагыйрь бар иде. Ул шагыйрь генә түгел, драматург, язучы һәм искиткеч шәп кеше дә иде әле. Кемнәрдер аны «Таныш моңнар», «Гашыйклар тавы» әсәрләре аша хәтерли; кемнәрдер «Кыр казлары артыннан», «Сандугачлар килгән безгә», «Бәхетемнән узып барышлый» кебек драмалары, моңсу - комедияләре өчен үз итә; кемнәрдер халык күңелендә үз урынын тапкан җырларыннан таный; ә берәүләр сабыйлар өчен язылган чишмә кебек ихлас, кояш кебек якты, иртәнге чык шикелле саф шигырьләре өчен якын итә, ярата.

Илдар абый чын балалар шагыйре дә иде. Абый җанлы гына түгел, сабый җанлы иде ул. Шуңадырмы ун елга якын балалар һәм үсмерләрнең «Сабантуй» газетасында эшләде.

Көн саен өем-өем хатлар, кочак-кочак шигырьләр ала. Балалар аны яраталар, Илдар абый да аларны үз итә.

Иҗат сөйгән эне-сеңелләрем,
Һәр көн сездән шигырь-хат алам.
Өстәлемә әйбәт әсәр килсә,
Үзем язган кебек шатланам, —

дип яза ул, бәхете ташыган шул мәлдә киләчәк буынга өмет тулы күзләре белән карап.

Әйе, Илдар абый мине дә Минзәлә педагогия көллиятендә укыган - чагымда балалар дөньясына, «Сабантуй» мәйданына бөтереп кертеп җибәрде. Ул күңелендә шигырь оеткысы булган яшь талантларны җаны белән тоя иде бугай...

Әсәрләрем газета битләрендә дөнья күрә торды, Илдар абыйның берсеннән-берсе җылы хатлары килә торды. Казанга килеп, университетка укырга керүемнең дә сәбәпчесе — ул.

Барлык төр жанрларда да иҗат иткән кеше киң күңелле буладыр, мөгаен. Ә балалар өчен иҗат итә алу, гомереңне шуңа багышлау — иң зур бәхет, минемчә.

Әлеге китапта урын алган шигырьләр арасында моңа кадәр дөнья күрмәгәннәре дә бар. Бу китап укучы күңелендә үз урынын табар дип ышанам, чөнки шагыйрь үзе дә:

Шигъриятле-җырлы юллар буйлап,
Әйдә, дуслар, бергә барабыз!
Сездән калышырга уйламый да
Илдар Юзи дигән бабагыз! —

дип, чиксез мәңгелектән безгә дәшә, көч-кодрәт, хәер-фатиха биреп тора.

*Ленар Шәех*

**Җил — парикмахер**

Көнләшәм мин тузганактан,
Беркем бәйләнми аңа.
Җил — бик оста парикмахер,
Тузганак чәчен ала.

Бармыйм мин чәч алучыга,
Шуңа күзем яшьле дә.
Әни килгәнче, җилкәем,
Алчы минем чәчне дә!

**Гаҗәп песи**

Гаҗәпләнеп карап
торам
Песиемә — Нәнигә:
Ашагач битен юа,
Кушмый әти, әни дә.

**Декабрь**

«Ай-яй салкын!» —
ди Кәбирә.
«Туңдыра бит!» — ди Кәбир.
Кулны-битләрне чеметә,
Ник шундый ул Декабрь?

«Ал чаңгыңны!» — ди Кадыйрә.
«Киттек тауга!» — ди Кадыйр.
Җитез булсаң, чаңгы шусаң,
Ягымлы ул Декабрь.

**Унбер малай... бер бал корты**

Тәрәзәне ачкан идек
Классны җилләтергә,
Бал корты да килеп кергән
Саф һава белән бергә.
«Уйныйбыз без!» дигән кебек,
Башта ул «без»ләп йөрде.
Әллә инде бал җыям дип,
Бер чәчәк эзләп йөрде.
Гөлчәчәкнең бантигына
Килде-кунды бал корты.
Ә ул: «Чага! Чага!» — диеп
Акырырга тотынды.
Барчасы да, өерелеп,
Ары да бире чапты.
«Тотыгыз! Тизрәк тотыгыз!
Гөлчәчәкне корт чакты!»
Әйттем: «Тотыйк та озатыйк
Болынына — иркенгә!»
Ишетергә теләмәде
Унбер малай — беркем дә.
«Юк! Юк!»
«Тотыйк та юк итик!»
«Ике канатын кисик!»
Унбер малайга берүзең
Каршы торасың ничек?
Нишләттегез нәни җанны,
Унбер яшь бала-чага?!
Кайвакытта корт чакмый шул,
Бал кортын бала чага.
Их, нәнием, ялгыштың шул,

Безне чәчәк, бал диеп,
Үзең кебек уйнаучылар,
Уйлаучылар бар диеп...

**Елак кыз**

Әнисе кебек, Айгөлнең
Рәссам буласы килә.
Рәсеме килеп чыкмагач,
Үкереп елыйсы килә.

«Болар дөрес ясамый», — ди,
Башка карандаш сорый.
«Әни, бүген үк алып кайт!» —
Үзе елый да елый.

Әнисе бик кызык иткән:
Алып кайткан фломастер.
Елак кыз рәсемен ясаган
Айгөл башка еламастыр.

Ай-һай, ул әнисе кебек
Чын мастер булалмастыр...

**Яз шикелле җылы абый**

Ерак әле нурлы язга,
Ерак, ерак…
Өчилесе тәнгә җылы
Бирер сымак.
Кайта Тукай, күренмичә
Авырып ята,
Бизгәк тота, мич башында
Калтырата.
Карый тышка тәрәзәдән:
Ай-һай суык!
Бозлы җирдә чабаталар
Китә шуып.
Хәллерәкләр киез итек,
Толып-туннан.
Күлмәк кигән малай килә
Карлы юлдан.
Нәни генә китап тотып,

Сабагына
Өтеп алган салкын кардан
Чаба гына.
«Теләк зур да, калмас микән
Туңып-арып,
Бу хәлендә җитәлерме
Язга барып?»
Чыга шагыйрь, йөзгә усал
Җил бәрсә дә.
Нәни эзләр алып бара
Мәдрәсәгә.
«Җылынырсың, мә, ал, шәкерт,
Киез итек,
Ки син аны абыеңның
Төсе итеп.
Бәхетеңә җиткәнгәчә
Йөгер инде.
Озак көткән язга ерак
Түгел инде.
Йөгергәндә калдырма тик
Китабыңны!
Сау бул, энем, син каласың,
Китәм инде».
Яз шикелле җылы абый
Сыйпый баштан,
Ал тәпинең сөенече
Күктән ашкан.
Яз шикелле җылы абый
Кышта калды.
Кермәде ул мәдрәсәгә,
Тышта калды.
...Язга чапты җылы итек
Кигән малай,
Куанычтан башы күккә
Тигән малай.
Юлда ташлап калдырмады
Китабын да.
Бәхетенә тизрәк чапты
Ул тагын да.
Еллар узды...
Берәү Тукай һәйкәленә
Карап тора.
Кышкы җилләр сирәк чәчен

Тарап тора.
Һәйкәлдә дә үзгәрмәгән,
Ул бит таный:
Яз шикелле җылы абый,
Олы абый!
Әйе, таный:
Җан сулышы белән эретеп
Боз һәм карны,
Үзе кышта калган бөек
Фидакарьне.
Шагыйрь абый үзе моны
Оныткан ул…
Миллионнарның күңелләрен
Җылыткан ул.

**Иң кызыгы**

Дәү әнием, ялкауланма,
Әйдә, сикереп тор да,
Икәү футбол тубы тибеп
Уйныйбыз коридорда!
Син алай итенгән бул,
Син болай итенгән бул...
Тупны тота алмадың ич!
Гол! Исәп: икегә ноль!
«Җитәр инде, ардым» димә,
Бик тә кирәк хәрәкәт.
Үзең әйтмешли, дәү әни,
«Хәрәкәттә — бәрәкәт».
Мин уйнап алам гармунда,
Биеп алсаң да ярый.
Китер кызыл яулыгыңны:
Мин — үгез, син — тореодор!
Үзең әйтмешли, дәү әни,
Бераз кирәк тырышлык.
Әйдә, сугышлы уйныйбыз,
Мә, кулыңа кылыч тот!
«Каты сукма!» дигән булып,
Күзләреңне кыскан бул,
Юри генә егылган бул,
Мин атам, син дошман бул!
Нишлисең син, дәү әнием,
Үпкәләп китмә алай!

Үзең әйтмешли, тыңламый
Үзәккә үтмә алай!
Дәү әни, нигә елыйсың?
Әллә авыртты кулың?
Ял итик, мин кәнфит ашыйм!
Син суыр валидолың.
Безнең өйдә һәр көн шулай
Күңелле ыгы-зыгы.
Мультфильм да кирәк түгел,
Дәү әни — иң кызыгы!

**Алма еште...**

Бот күтәреп ята идем...
Ярый, шәп, эшләр еште...
Әни, алмагачка менеп,
Алма җыярга кушты.

Якшәмбе көн — ял итим лә...
Тагын әйткәнне көтим.
Маймылдай анда менгәнче,
Алмагачны селкетим!

Әтием яки абыем
Эшләсен мондый эшне!
Алар җыйганны ашарга
Авыз әзер, кәнишне!

«Алма, пеш, авызга төш!» —
дип
Ятам аяк селкетеп,
Татар халык мәкаленең
Туры килгәнен көтеп.

Селкеткәнне дә көтмәде,
Бер алма килеп төште.
Авыз пеште... Әллә-лә-лә...
Ахрысы, башны тиште.

**Бала хыялы**

Салкын урамда бер бала
Акча салганны көтә.
Байлары да, ярлысы да

Аны күрмичә үтә.

Алдында — искереп беткән
Уенчык машинасы.
Бар хыялы — ашамыйча,
Бик күп акча җыясы!

Беркөнне аны балалар
«Жигули»да күрерләр,
«Мине утырт! Мине!» — диеп,
Артыннан йөгерерләр.

**Самат телеграмма суга**

Самат туйган озын җәйдән,
Эссе кояш, җилләрдән...
«Кыш Бабайга бирергә!» дип,
Телеграмма җибәргән:

«Кил, Кыш Бабай, үзең белән
Кучтәнәчләр алып кил.
Капчыгыңа мин яраткан
Бик дәү карбыз салып кил!»

Самолетка утырган да
Чыгып киткән Кыш Бабай.
Кар-бураннарны туздырып
Килеп җиткән Кыш Бабай.

Көтә Самат... Капчыкта юк
Ул көткән карбыз гына...
Кыш Бабасы алып килгән
Салкын кар һәм боз гына.

**Татар аюыннан хат**

Аю күргәнегез бармы?
Мөгаен, юктыр.
Сез күргән аюлы урын —
Зоопарктыр.
Ә мин урманның үзендә
Күрдем чыннан да,
Күрше удмурт якларында,

Кара урманда.
Шул аю белән бик озак
Сөйләшеп яттым.
Ул ялваргач, сезгә шундый
Хат алып кайттым:
«Сәлам сездә туган татар
Аюларыннан,
Сәлам Кояшның бик моңсу
Баюларыннан.
Сәлам безнең белән киткән
Кошлар санынча,
Илен сагынып саргайган
Дуслар санынча.
Әгәр белсәгез иде сез
Качкыннар хәлен,
Күрмибез тыныч шаулаган
Урманның ямен.
Кош сайравын туган якта
Тыңлыйсы килә,
Сагынганда, бүре булып
Улыйсы килә.
Җәен өем булыр иде
Куе урманым,
Кышын ябынып ятар идем
Ап-ак юрганын.
Кайтсам, бу чит урманнарны
Сагынмас идем,
Сорамыйча, умартага
Кагылмас идем.
Кайтсам, сез дусларым белән
Кавышыр идем,
Иң-иң эре җиләкләрне
Табышыр идем.
Язам моны ап-ак ташка
Башымны куеп,
Кардай кәгазь битләренә
Яшемне коеп.
Беләсездер безне су да,
Ут та куганны.
Су астында калдырдылар
Күпме урманны!
Анда малайлар кабызган
Учак дөрләде,

Урманның янып киткәнен
Алар күрмәде.
Тирләдек, пештек утларда,
Таныйрлык түгел,
Үзебез туган урманда
Калырлык түгел.
Куркыттылар, без болай да
Аз була торып,
Урманны мичкә яктылар,
Газ була торып.
Чигенә-чигенә, килеп җиттек
Иң соңгы чиккә.
Без әйләндек качкыннарга
Ят җирдә — читтә.
Шулай каңгырып, тилмереп
Ятыйммы инде?
Анда урманнар исәнме?
Кайтыйммы инде?
Җавап булса, юл чыгармын
Хатны алгач та,
Туган ягым Әгерҗегә
Яки Балтачка.
Язам моны ап-ак ташка
Башымны куеп,
Кардай кәгазь битләренә
Яшемне коеп».

**Их, малайлар!**

Калкавычка карый-карый,
Ике күзем ялыкты.
Тотмый калмам,
Их, малайлар,
Менә мондый балыкны!

Тизрәк, балык, кап!
Кармагымны кабып тарт!
Малайларны көнләштереп,
Яр башында ялтырап ят!

Калкавычым су төбенә
Бер батты, бер калыкты.
Ычкындырдым,

Их, малайлар,
Менә мондый балыкны!

Тизрәк, балык, кап!
Кармагымны кабып тарт!
Малайларны көнләштереп,
Яр башында ялтырап ят!

Кармакны тартып чыгардым —
Шаккатырдым халыкны.
Ычкындырдым,
Их, малайлар,
Үземнән зур балыкны!

Тизрәк, балык, кап!
Кармагымны кабып тарт!
Малайларны көнләштереп,
Яр башында ялтырап ят!

**Кинодагы кебек**

Утырдылар парталарга,
Тәнәфестән кереп,
Телевизордан караган
Кинодагы кебек.

Шамил ташланды Камилгә,
Җиңәчәген белеп,
Телевизордан караган
Кинодагы кебек.

Камил Шамилне очырды
Аяк белән тибеп,
Телевизордан караган
Кинодагы кебек.

Укытучы куркып калган,
Мондый хәлне күреп,
Телевизордан караган
Кинодагы кебек.

Малайлар ята идәндә...
Класс тора көлеп...

Телевизордан караган
Кинодагы кебек...

**Әбием экиятенең дәвамы**

Энәсенә күз иярми,
Әбием кызып киткән.
Әкиятләр сөйли миңа,
Иллә дә кызык икән:
«Ул киткән,
Ай киткән, ел киткән,
Энә буе җир киткән...».
Сизмәдем дә, кай арада
Йомгак сүтелеп беткән?!

...Кеше сәфәргә киткән.
Оек бәйләп бетергәнче,
Айга ук барып җиткән.

**Шомбай эшләп арыган...**

Иртән торгач, әнисе
Йомыш кушкан Шомбайга.
Шомбай әйткән:
— Юк, булмый,
Мин бик ардым болай да...

— Әле генә уяндың,
Шомбай, син ничек ардың?
— Һай, бик ардым, бик ардым:
Иртүк кибеткә бардым,

Утын кистем дә ярдым,
Боз тишеп, кармак салдым,
Зур чуртан тартып алдым...
Һай, бик ардым, бик ардым...

— Алдыйсың ич, боларны,
Мөгаен, төштә күрдең?
— Әйе шул, төштә күрдем.
Мин бит гел эштә йөрдем...

**Онықка сөйләгән әкият**

Борын-борын заманда,
Син әле тумаганда,
Әниең булмаганда,
Бабаң әбиеңне белмәгәндә,
Аны төштә дә күрмәгәндә,
Булмаган, ди, чаңгы да,
чана да.
Бабаң шуган, ди, табада,
Теләгән әбиеңне табарга!
Әбиең тиз йөгергән,
тоттырмаган,
Ул бит табага утырмаган.
И чапкан әбиең, и чапкан,
Ычкынмак булып кочактан.
Бабаң атланган бер атка,
Чапкан ике-өч көн, бер атна.
Беркөнне куып
җиткән сөйгәнен,
Көткән «Мин дә сөям!»
дигәнен.
И чапканнар болар,
и чапканнар,
Бәхетләрен бергә тапканнар.
Әтиеңне эзләп киткәннәр,
Әниеңне эзләп киткәннәр.
Тракторга утырып,
Самолетка утырып,
Сине эзләп киткәннәр
Һәм, табып,
Дөньяга сине бүләк иткәннәр.
Синеке бу замана,
Утырма чанага.
Эзләп торма таба.
Ракетага утыр да
Оч киләчәккә таба.
«Эзләгәнне таптым» диярсең,
Онычыңны сөярсең...
«Борын-борын заманда» дип,
Әкиятләр сөйләрсең...

**Кәбестә белән Кишер**

Кышын күңелле инде ул,
Урамда җылы булса,
Кәбестәнеке шикелле,
Җиде кат туның булса.

Бүген бигрәк тә суык шул:
Утыз ике градус.
Тәрәзәдән бик кызыгып
Карап тора ике дус:

Озын аяклы Кишер һәм
Олы башлы Кәбестә.
Малайлар ничек туңмыйлар,
Туннары да юк өстә.

Һич кенә дә тик тормыйлар:
Берсе күрсәтә фокус,
Ике малай уйный бокс,
Өченчесендә — кукиш!
Берсе куллана каратэ,
Берсе йөри кар атып,
Берсе карны өеп китә,
Икенчесе — таратып.

Кишер әйткән: «Өйдә ятып
Туйдым, чыгабыз!» — дигән.
Кәбестә: «Анда салкында
Ничек чыдарбыз?» — дигән.

«Хәрәкәттә — бәрәкәт!» дип,
Бабайлар белеп әйткән!
Кишер олы башлы дустын
Урамга тәгәрәткән.

Кишер тышка чыгу белән
Йөгерергә тотынган.
Ә Кәбестә: «Туңам!» — диеп
Утырган да утырган.

«Җылы өйгә кертегез!» —
дип
Яткан да яткан икән.
Кузгата да алмаганнар,

Боз булып каткан икән.

Килгән Кишер: тәне алсу,
Битләре дә алланган.
Кәбестәне тәгәрәтеп
Өйгә кертә алмаган.

Кайткач тиргәгәннәр аны:
«Бераз уйларга иде,
Ник ташладың, дустың белән
Бергә уйнарга иде...».

**Чыпчык бәйрәме**

Чырык-чырык-чырык чырлыйбыз,
Үзебезнең көйгә җырлыйбыз:
Бездә бүген чыпчык бәйрәме,
Син дә кушыл безгә, әйдәле!

Озын кыштан исән-сау чыктык,
Салкын көннәрендә чыныктык.
Бездә бүген чыпчык бәйрәме,
Син дә кушыл безгә, әйдәле!

Чырык-чырык-чырык, чык-чырык,
Без унике... утыз... йөз кырык.
Бездә бүген чыпчык бәйрәме,
Син дә кушыл безгә, әйдәле!

Тавыш сандугачка иш түгел,
Ямьле язда җырлый ич күңел.
Бездә бүген чыпчык бәйрәме,
Син дә кушыл безгә, әйдәле!

**Тукта, ник качасың?**

Әллә төштә, әллә өндә,
Әллә кичен, әллә төнлә —
Бара Сәгыйть урам буйлап,
Бик куркыныч уйлар уйлап:
«Килеп чыкса бер юлбасар
Йә хулиган — кая качар?»
Ишетә ул ят бер тавыш:

«Сәгыйть, кая китеп барыш?»
Аяклары тими җиргә,
Тотына ул йөгерергә.
Шүрләмәгән икән юкка:
Арттан тавыш: «Сәгыйть, тукта!»
Ә монысы тимәс кебек,
Салмак тавыш киңәш кебек:
«Бездән куркып калгансыңдыр,
Хәл җый туктап, аргансыңдыр».
Һаман чаба, чаба Сәгыйть,
Хәлдән таеп ава Сәгыйть.
Куучылар ала урап,
Сәгыйть мескен ята елап:
— Ник кудыгыз? Ник тоттыгыз?
— Сез кемнәр? Ник куркыттыгыз?
— Сорау биргәч, ник дәшмәдең?
— «Хәл җый» дигәч, сөйләшмәдең.
— Туктамадың, «Тукта!» дигәч.
— Егылдың, мин — Нокта килгәч.
— Безне артык дип уйлыйсың,
Язган чакта ник куймыйсың
Сорау, Өндәү, Нокта, Өтер?
Яле, дәфтәреңне китер!
Сәгыйть торып утырган, ди,
Сүз биреп чак котылган, ди:
— Онытмамын һәр җөмләдә,
Көндезен дә һәм төнлә дә.
Яшәү рәхәт хата юкта. —
Ялгышларга куям Нокта!

**Макай белән Акбай**

Макай чанада яткан —
Акбай чананы тарткан.
Макай мәктәптән качкан —
Акбай букчасын капкан.

Макай төнен йоклаган —
Акбай аны саклаган.
Макай батмый чак калган —
Акбай аны коткарган.

Акбай чирли башлаган —

Макай аны ташлаган.
Акбай салкында туңа —
Макай җылыда куна.

Кочакладым Акбайны:
«Оныт, — дидем, — Макайны!»

**Мокыт барган кунакка**

Корсакка өя-өя
Тутырган гөбәдия,
Ярты тавык, ярты каз...
Мокыт әйткән: «Бу бик аз!»

Төягән ул мең борчак,
Сиксән ике бавырсак,
Кырык фасоль, йөз ногыт
Капкан да йоткан Мокыт.

«Ой, бигрәк тәмле дә соң!» —
Ялаган тәлинкәсен.
Ашаган ул шулчаклы —
Кибән иткән корсакны!

Рәхмәт әйтәсе урынга
«Тагын бир!» дип кычкырган.
Төчкергәндә, пошкырганда,
Нәрсәседер ычкынган.

Һәммәсе дә Мокыт өчен
Кызарып утырганнар.
Күтәргеч кран чакыртып,
Чак кына котылганнар.

Утыртсаң — яткырып булмый,
Тора алмый — яткырсак.
Безнеке ул — вак корсак,
Мокытныкы — вот корсак!

Үз исеме онытылды,
Мокыт хәзер —
«КАПКОРСАК»!

**Ике дус**

Ике Мыраужан урманга
Баралар икән кереп...
Алларына килеп чыккан
Маэмай «һау!» да «һау!» өреп.

Бер Мыраужанның куркудан
Коты ботына җиткән:
Дустын берүзен кадырып,
Агачка менеп киткән.

Икенчесе — тәвәккәле —
Маэмайның көчен белгән,
Тәпиләре белән сугып,
Тегене чигендергән.

Маэмай әйткән: «Моннан соң без,
Әйдә, дус булыйк! — дигән. —
Юлда очраган куркаклар
Белән хушлашыйк», — дигән.

Агач башындагы Мырау...
Күзләре ялтырый, ди,
Үзе генә түгел, хәтта
Агач та калтырый, ди...

**Балык малай каптыра**

Мин, балык, яр буенда
Малайларны каптырам:
Тфү! Тфү! Малай, кап!
Аптырап карап торам.

Тфү! Тфү! Малай, кап!
Берсе дә эләкмиләр.
Юри генә каптырам!
Берсе дә кирәкмиләр!

Ятьмә тотып, аларны
Бик тә сөзәсе килә,
Ярга атып, һәммәсен
Җепкә тезәсе килә!

Мин, балык, яр буенда

Малайларны каптырам.
Юк, каптырмыйм, аларга
Кызыгып карап торам.

Үзегезнең кармакка
Ялгыш килеп капмагыз.
Ябышыгыз таякка, —
Су бик тирән, батмагыз!
Тфү! Тфү! Капмагыз!

**Гөл нигә шиңгән?**

Бик эссе көннәрдә
Барсы су сорыйлар.
Сипмәсәң — шиңәләр,
Кибәләр, корыйлар.

Бакчада гөлләргә
Самат та сибә су.
Сипсә дә, гөлләре
Шиңәләр нигә соң?

Самат, бик әлсерәп,
Шул суны эчкән, ди,
Беркөнне, авырып,
Тамагы шешкән, ди.

Аңлаган Самат та,
Терелеп көч кергәч:
Үсми гөл эсседә,
Салкын су эчергәч...

**Карбыз белән Фәрваз**

Фәрваз карбыз ашаган.
Карбыз бик тә ошаган.
Берне, өчне ашаган,
Берчак арта башлаган.

Кайсы карбыз, кайсы Фәрваз?
Ни әйтсәң дә ышанам.
Карбыз кемгә охшаган?

Ул Фәрвазга охшаган.

Әйт, кемне кем ашаган?

**Попугай**

Ул басып тора
Такта янында,
Ә колаклары —
Парта ягында.
Яшереп тормыйм,
Исеме — Барый.
Әйтегез диеп,
Гел безгә карый.
Нәрсә әйтсәң дә,
Шуны кабатлый.
Аның гадәтен
Беркем яратмый.
Попугай диеп
Таралды даны.
Бик күп кешеләр
Сорыйлар аны.
Моны ишетеп,
Бер абый килде:
«Шул попугайны
Зоопаркка
Бирегез», — диде.
Ә без Барыйны
Бик нык кызгандык:
«Ул — Барый бит», — дип,
Чак алып калдык.
Барый кабатлый:
«Абый, кит инде,
Попугай түгел,
Барый бит инде».
Ләкин һаман да
Түзәлми Барый,
Әйтегез диеп,
Гел безгә карый.
Ахры, Барыйдан
Бик нык туярбыз.
Чынлап та аны
Зоопаркка

Илтеп куярбыз.

**Карга күмелгән Аю**

Киселгән агач төбеннән
Бер шешә тапкан Аю.
Адәмнән калган хәмерне
Кызыгып капкан Аю.

Салкын көз көне булса да,
Сизмәгән кар-суыкны.
Имәнгә бәйләнә икән:
«Яратасыңмы, юкмы?»

«Нишләп юлымда
торасың?!» —
Бүрене болгап аткан.
«Сине уважаю!» диеп,
Керпене кочып яткан.

Тиенне тотып ашыйм дип,
Нараттан егылып төшкән.
Тиеннәр көлгән тәгәрәп,
Ә Аю... башын тишкән.

Айнырга да өлгермәгән,
Кыш килеп җиткән, диләр.
Беркем уята алмаган,
Кар күмеп киткән, диләр...

**Ике хыял**

Карагыз әле Ләйсәнгә:
Ул кем булырга тели?
Кулына таяк тоткан да
Дәү әни кебек йөри.
«Дәү әни булыр идем дә
Эшләми арыр идем,
«Пенсиямне бирегез!» — дип,
Кассага барыр идем,
Кассага барыр идем дә
Күп акча алыр идем,

Кырык бер чупа-чупсны
Кесәгә салыр идем,
Калган акчама Ләйсәнгә
Торт сатып алыр идем,
Иртән торгач та, мәктәпкә
Бармыйча калыр идем,
Өчпочмак, бәлеш ашарга
Кунакка барыр идем...»
Алай шаярма ла, Ләйсән,
Таягыңны куй әле.
Инде үзең тыңлап кара
Дәү әниең хыялын:
«Их, балалар, могҗизалы
Дару табасы иде,
Балачакка кайтасы да
Торып чабасы иде!
Ләйсән яшенә кайтсаммы?
Ардым, дип ятмас идем,
«Әби буласы иде!» дип,
Хыялга батмас идем,
Ләйсән кебек кенә булсам,
Мин анда кайтмас идем».

**Каз бәбкәсе**

Каз — әнкәсе.
Аз бәбкәсе.
Саклана күр,
Каз бәбкәсе!

**Экрандагы Әкрам**

Америка киноларын
Бик ярата Әкрам да.
Үзен бик күрәсе килә
Әнә шундый экранда.
Безнең мәктәп — «телевизор»,
Тамашачы булыгыз!
Килегез дә тәнәфестә
Читтән карап торыгыз.
Зур залга да сыялмыйча,
Килеп чыгар «экран»нан.

Алдыңда торса, — һәммәсе
Куркып кача Әкрамнан.
Кем соң ул Әкрам дисезме?
Сезгә әллә кем түгел...
Америка фильмындагы
Ковбойлардан ким түгел...
Карагыз әнә, ул нишли?
Уртага ялгыз чыга,
Уйламый да, уйнамый да, —
Бишәүне сугып ега!
Әнә ничек басып тора:
«О,кей!» дип тор син аңа.
Кесәсеннән ут чыгара,
Авызында — сигара.
Күрдек инде, тия алмый
Үзеннән көчлеләргә,
Әкрам супербатыр икән
Үзеннән кечеләргә.
Сиздермичә, камерага
Төшереп алдым мин аны.
Күрсәтербез үзенә дә
Үзебезнең киноны!

**Кар өстендә дөяләр**

Шыгыр-шыгыр баса алар
Салкын кар өсләренә.
Эссе чүлләр, кайнар комнар
Керәдер төшләренә.

Казан урамыннан уза,
Башын иеп дөяләр.
«Сезнең туган җирегез бар,
Сез бәхетле...» — ди алар.

**Шукбайның Йабкуш белән очрашуы**

Әйткәннәр: «Бардыр ич синең
Үз туганнарың...
Без дә белергә телибез,
Әйт булганнарын?»
«Берсен дә белмим, —

ди Шукбай, —
Исем китми дә...
Их, туганың булса иде
Ерак чит илдә!
Бардыр, мөгаен. Ул миңа
Килергә тиеш,
Мине эзләп табарга һәм
Күрергә тиеш!»
Башкалар да аның белән
Бергә көтәләр.
Чыннан да, килеп, Шукбайга
Хәбәр итәләр:
«Сорый берәү: Шукбай туган
Сездә яшиме?
Теле — безнең нәкъ киресе,
Йабкуш — исеме».
Шукбай атлап кына бармый,
Бара гел чабып.
Малайлар каршы алалар
Аны кул чабып.
«Күрсәтегез, кайда Йабкуш —
Якын туганым?
Чакырсын, минем ул илдә
Юк бит булганым...»
Сөенечле минутларны
Тора ул көтеп.
«Менә ул!» —
Берсе Шукбайны
Күрсәтә төртеп:
«Тагын бер Шукбай
барлыгын
Күрдең ич инде,
Үзең белән очрашырга
Килдең ич инде!
Үзеңне һәм нәселеңне,
Бәлки, белерсең...
«Йабкуш» сүзен ипләп кенә
Укы киресен:
Ш У К Б А Й!»

**Мияубикә нигә боек?**

Мияубикә ник уйнамый?

Күзләре боек аның...
Тәрәзәдән карап тора:
Үз әнисе юк аның.

Дәү әнием, дәү әтием
Аны да үз итәдер.
Мин генә аңлыйм: сагынып,
Ул әнисен көтәдер...

**Шайтан котырта...**

Шайтан котырта Камилне:
— Алдыңда ич компьютер.
Дәресеңне әзерләмә,
Көн буе өйдә утыр!

Шайтан котырта Шамилне:
— Алдыңда — телевизор.
Кулга китап алмасаң да,
Рәхәттә гомер узар.

Әйт син, Камил дә, Шамил дә:
— Шайтан, безне котыртма!
Көн буе өйдә яткырып,
Төп башына утыртма!

**Плюс белән Минус**

Плюс белән Минус берчак
Дәресне ташлаганнар,
Коридорга чыкканнар да
Талаша башлаганнар.
Минус әйткән: «Син бик комсыз,
Хәйләгә бик остасың,
Миңа тиеш булганны да
Гел үзеңә кушасың».
Плюс әйткән: «Ә син миннән
Кушканны да аласың,
Ала-ала, ала-ала,
Өстен булып каласың».
Минус әйткән: «Җитте! — дигән.—
Плюс буласым килә.

Гел үземә куша-куша,
Тормыш корасым килә!»
Шулай дигән дә бар көчкә
Плюска сылаган, ди,
Ике чаты сынган Плюс
Үкереп елаган, ди.
Дәрестә калган балалар
Кушканнар да алганнар.
Ә тегеләр икесе дә
Минус булып калганнар.

**Шомбай шәп шигырь язган!**

Шомбай шәп шигырь язган!
Озак уйлап тормаган,
«Үзем уйлап чыгардым!» дип,
«Сабантуй»га юллаган.
«Шагыйрь булдым!» дип, борынын
Чөйгән ул югарыга:
«Минем кебек талантлылар
Дөньяда юк әлегә!
Менә күрерсез, бер капчык
Акча да килеп төшәр,
«Сникерс» белән тулыр,
Сай булмас минем кесәм.
«Бөек шагыйрь Шомбай» диеп,
Һәйкәлемә уярсыз.
«Монда Шомбай укыды!» дип,
Такта элеп куярсыз.
Калтырана-калтырана,
Имтиханга керерсез.
«Шомбай фәлән елда туган», —
Диеп җавап бирерсез».
Бик шәп шигырь язган Шомбай!
Белмәсләр дип уйлаган,
Үз исемен генә язган,
Чын авторын куймаган.
Шукбай язган җавап хатны
Яшергән ераккарак:
«Шагыйрьдән күчереп язган,
Авторы моның — карак!»

**Моңнар тулды йөрәгемә**

Бер кыз бик тә ошый миңа,
Әйтергә дә оялам.
Төшемдә дә, өнемдә дә
Гармун уйнап моңланам.

Җырлар тулды йөрәгемә,
Мин инде бала түгел.
Гармунга ачсам серемне,
Сафланып кала күңел.

Үзем уйныйм, үзем җырлыйм:
«Яна минем йөрәгем...»
Моңа кадәр йөрәгемнең
Ни икәнен белмәдем.

«Яна минем йөрәгем...» дип,
Гармун уйныйм өздереп.
Уйна, гармун, моңлан, йөрәк,
Үзенә дә сиздереп.

**Мине кем аңлар?**

Нинди күңелле
Яшәгән идек!
Бергә җырладык,
Уйнадык-көлдек.
Онытты бергә
Җырлаган көйне,
Кайтмый әтием,
Сагынып өйне.
Ике канатым
Ник каерылды?
Әти һәм әни
Ник аерылды?
Бер-берсен сөеп,
Ник карамыйлар?
Бер-берсен алар
Ник аңламыйлар?
Йөрим мин ике
Өй арасында,
Ике йөрәкнең
Бер ярасында.

Йоклый алмыйча
Сызыла таңнар.
Нишләргә инде,
Мине кем аңлар?
Йөрим мин ике
Өй арасында,
Өзелеп калган
Көй арасында...

**Елады...**

Еламый Айнур беркайчан:
Бәрелсә, сугылса да,
Кыйналса да, йөгергәндә
Абынып егылса да.

Дәрестә шаян булуын,
Ахры, истә тоттылар:
Дусты Булаттан аерып,
Кыз белән утырттылар.

Бар сыйныф алдында Айнур
Елады яшь тамызып.
Айнур елый, барсы көлә,
Табалардыр ни кызык?

Мин эчтән генә еладым,
Көлалмадым кушылып.
Янда Камилә булмагач,
Нидер калды буш булып...

**Хатасыз ничек язарга?**

Дәрестә — диктант. Хатасыз
Язарга ничек кенә?
Артта утырган Фәритнең
Тавышы ишетелә:
«Алло! Алло! Әни! Синме?
Үзең белмәсәң, эзлә!
Әйт тиз генә:
«И»ме, «е»мы
«Телефон» дигән сүздә?»

**Соңга калган...**

Һәрбер бала килеп
Үз урынын алган.
Бары Мидхәт кенә
Никтер соңга калган.

Укытучы сорый:
«Синме соң бу, Мидхәт?
Җәяү килдеңме әллә?
Соңга калдың нишләп?»

Әйтте Мидхәт: «Сез... нәрсә?!
Җәяү йөримме соң?!
Әти машинасы
Килде бүген бик соң...»

**Ни булган Вахитка?**

Булмый ич танып та,
Ни булган Вахитка?
Шулкадәр үзгәрде
Ул соңгы вакытта.
Киләләр өенә:
«Уйнарга, Вахит, чык!»
«Йөрмәгез буталып,
Эшем күп! Вакыт юк!»
Башына кияргә
Алдырган эшләпә.
Өй эшен күршесе
Хәмиттән эшләтә.
Коллектив бәдрәфкә
Вакланып йөрми дә.
Башкалар көлгәндә,
Елмаймый-көлми дә.
Классның ишеген
Яба ул шап итеп,
«Волга»ның ишеген
Япкандай шәп итеп.
«Сез нәрсә? Макарон
Мин ашап тораммы?

Бирегез әфлисун!
Табыгыз икраны!»
Бер чегән хатыны
Юраган, имештер:
«Үскәч тә син, энем,
Буласың министр!»
Хыялда бул әйдә,
Кылан һәм килештер,
Чынында булырсың
Микән син министр?..

**Чын очышка әзерлек**

Хыялланам күптән мин,
Килеп төштем күктән мин!
Өнме бу, әллә төшме?
Ракетам кая төште?

Һуштан яздым дисәм мин —
Күзләр ачык — исәнмен!
Урманда карга чумдым,
Чып-чын космонавт булдым.

Таудан очтым чанада.
Бу очканга санала:
Чын очышка әзерлек.
Теләк, хыял хәзер нык.

Егылып ятмас алай
Карга күмелгән малай.
Аерылыр чанадан,
Күктән төшәр яңадан!

Эзләрләр вертолетлар.
Табып, дусларым котлар.
Чынлап төшәр урын бу —
Ракетодром бу!

**Иртәнге серенада**

Кичтән ябылмыйча калган
Клавишалар буйлатып
Нәни песи йөгереп уза
Сиринәне уятып:

«До-ре-мияу, мияу-мияу,
Мин инде күптән уяу!
Фа-соль-ля-си... Сиринә,
Торырга вакыт сиңа!»

Һич тә кузгата алмагач,
Килә дә Сиринәгә
Көйгә кушылып җырлый ул
Иртәнге серенада:

«До-ре-мияу, мияу-мияу,
Мин инде күптән уяу!
Фа-соль-ля-си... Сиринә
Уяныргa иренә».

Бик тиз генә сикереп тора
Дәртләнеп Сиринә дә,
Җырлый мияуга кушылып
Иртәнге серенада:

«До-ре-мияу, мияу-мияу,
Без инде күптән уяу!
Фа-соль-ля... Сиринә дә
Башкара серенада!»

* * *

Агыйделдә балык тоттым,
Сөзә белмәсәм дә мин.
Атка менеп, елга кичтем,
Йөзә белмәсәм дә мин.

* * *

Син, Камилә, камыр бас,
Син табаны тот ипләп.
Дәү әнине тәбрикләп,
Пешерәбез тәбикмәк.

* * *

Борын-борын заманда
Шүрәле булмаган, ди,
Кәҗә дә булмаган, ди,

Сарык та булмаган, ди,
Әкиятләр язарга
Тукай да тумаган, ди.

* * *

Борын-борын заманда,
Машинасыз чакларда,
Җәяү йөргән атлар да,
Җәяү йөргән хатлар да.

* * *

Кунакка чакырдым
Бүре белән Куянны.
Куян килмәде.
Уйлагандыр:
«Кишер куярмы?»
Кыяр бирдем.
Бүре ашамады кыярны.
Ул Куянны көтте.
Арып бетте.
Көтә-көтә туйды.
Мине дә ашап куйды...

* * *

Аю килгән бал урларга,
Кортлар авызын чаккан.
Мескен Аю, елый-елый,
Урманга таба чапкан.

* * *

Паркка баргач, әтием
Атландырды дөягә.
Дөя, мине генә утырт,
Бала-чага төямә.

* * *

Бал кортлары очып йөри. —
Никтер мине чакмыйлар.

Чәчәк диеп уйлыйлармы? —
Мине дә кочаклыйлар.

* * *

Дәү әтием минем өчен
Уйлап таба такмакны.
Мин самавыр кайнатырга
Ваклап торам шакмакны.

* * *

Бик акыллы патшаны һәм
Бер тиле вәзир күрдем.
Әллә төштә, әллә инде
Телевизорда күрдем.

* * *

Әти-әни бик-бик матур
Кәпәч алып бирделәр.
Урамга чыгып кычкырма,
Әтәчләнмә, диделәр.

* * *

Качышлы уйнаганда,
Аю калган көлкегә.
Күзләре бәйләнгән ич аның, —
Килеп баскан Керпегә.
Ой, күрсәгез иде аның
Коточкыч үкергәнен,
Урманына кача-кача,
Бер метр сикергәнен.

* * *

Биш куянга биш кишер
Үстермәдем бакчада.
Базардан да алыр идем, —
Кесәмдә юк акча да.
Биш куянымны саттым,
Акчам да бар кесәмдә.

Куяннан да тизрәк үсәм,
Кишер суы эчәм дә.

* * *

Саескан түбән очкан,
Урлашып күкәй эчкән.
Тавыктан качып барганда,
Егылып башын тишкән.

* * *

Сөйлим микән, сөйләмимме
Бүрегә юлыкканны.
Әмма сөйләмәскә булдым
Куяннан курыкканны.

# ЭЧТӘЛЕК

Сабый җанлы Илдар абый. *Л. Шәех* ..

Җил — парикмахер .......

Гаҗәп песи .......

Декабрь .......

Унбер малай... бер бал корты ...

Елак кыз .......

Яз шикелле җылы абый ......

Иң кызыгы .......

Алма пеште... .......

Бала хыялы .......

Самат телеграмма суга .....

Татар аюыннан хат .......

Их, малайлар! .......

Кинодагы кебек .......

Әбием экиятенең дәвамы ....

Шомбай эшләп арыган... ...

Оныкка сөйләгән экият ....

Кәбестә белән Кишер ......

Чыпчык бәйрәме .......

Тукта, ник качасың? .......
Макай белән Акбай .......
Мокыт барган кунакка ......
Ике дус .......
Балык малай каптыра .......
Гөл нигә шиңгән? .......
Карбыз белән Фәрваз .......
Попугай .......
Карга күмелгән Аю .......
Ике хыял .......
Каз бәбкәсе .......
Экрандагы Әкрам .......
Кар өстендә дөяләр .......
Шукбайның Йабкуш белән очрашуы ...
Мияубикә нигә боек? .......
Шайтан котырта... .......
Плюс белән Минус .......
Шомбай шәп шигырь язган! .......
Моңнар тулды йөрәгемә .......
Мине кем аңлар? .......
Елады... .......
Хатасыз ничек язарга? ....
Соңга калган... .......
Ни булган Вахитка? ......
Чын очышка әзерлек ......
Иртәнге серенада .......
«Агыйделдә балык тоттым...» ...
«Син, Камилә, камыр бас...» ..
«Борын-борын заманда...» ...
«Борын-борын заманда...» ...
«Кунакка чакырдым...» ...
«Аю килгән бал урларга...» ...
«Паркка баргач, этием...» .......
«Бал кортлары очып йөри...» ..
«Дәү этием минем өчен...» ...
«Бик акыллы патшаны...» .....

«Әти-әни бик-бик матур...» .....
«Качышлы уйнаганда...» .....
«Биш куянга биш кишер...» .....
«Саескан түбән очкан...» ......
«Сөйлим микән, сөйләмимме...» .....

Литературно-художественное издание

Для детей младшего и среднего школьного возраста

**Юзеев** Ильдар Гафурович

## ВЕРБЛЮДЫ НА СНЕГУ

Составитель
**Шаехов** Ленар Миннемохимович

Казань. Татарское книжное издательство. 2008

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

Кече һәм урта яшьтәге мәктәп балалары өчен

**Юзеев** Илдар Гафур улы

## КАР ӨСТЕНДӘ ДӨЯЛӘР

Төзүчесе
**Шәехов** Ленар Миңнемөһим улы

Мөхәррире *Т.Р.Шакирова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректоры *Г.Х.Сундукова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 17.01.2008. Форматы 60□108 $^{1}/_{16}$.
Офсет кәгазе. «School Book» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 4,80. Шартлы буяу-оттиск 19,80. Нәшер-хисап табагы 3,98.
Тиражы 5000 д. Заказ К-12.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

http://tatkniga.ru
E-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.